# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Юл хәрәкәте, транспорттан файдалану һәм транспортны саклау, юл-урам челтәрен һәм хәрәкәтне оештыруның техник чараларын тоту кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

I. "Юл хәрәкәте, транспорттан файдалану һәм транспортны саклау, юл-урам челтәрен һәм хәрәкәтне оештыруның техник чараларын тоту кагыйдәләрен бозган өчен административ җаваплылык турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. 4 статьяда "бер ярым" дигән сүзләрне "икедән алып өчкә кадәр" дип алмаштырырга.

2. 6 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"бер ел эчендә кабатланган шул ук гамәлләр өчен, -

транспорт чараларын йөртү хокукыннан өч елдан алып биш елга кадәр мәхрүм ителә яисә биштән алып җиде минималь хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына".

3. 8 статьяның беренче өлешен төшереп калдырырга, элеккеге икенче һәм өченче өлешләрен беренче һәм икенче өлешләре дип санарга.

II. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 13 июле

№ 1928-XII